وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт


№13 (182). 29 март 2013 / 17-җөмәдиәләүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең ярдәмчеләре белән таныштырды

▷2◁



Имам, тарихчы, этнограф

▷3◁



Мөслимәләрнең эшлекле стиль үзенчәлекләре

▷4◁

# БЕРГӘЛӘП КУЙГАН МАКСАТЛАРЫБЫЗГА ИРЕШЕРБЕЗ

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**
**Әссәламегаләйкүм**
**вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!**

Моннан ике ел элек узган корылтайда эшебезне хәнәфи мәзһәбенә һәм матуриди гакыйдәсенә туры китереп алып барырга килештек. Бу карар безнең барлык гамәлләргә: дәгъватка, дини йолаларны үтәүгә, эчке сәясәткә һәм халыкара мөнәсәбәтләргә дә кагыла. Эшебез алга таба да шул юнәлештә дәвам итәр, иншә Аллаһ.

Хәзер бу хакта артык сөйләп тормыйм, кайбер мөһим проблемаларга кагылышлы фикерләремне генә җиткерәм.

Беренчедән, нәзарәтнең төп эше бергәлеккә, үсешкә омтылыш булырга тиеш. Дөрес, безнең кайбер карашлар туры килмәскә дә мөмкин, без бит төрле. Аллаһы Тәгалә безне шундый итеп яраткан. Әмма барыбыз да - мөселманнар, шуңа күрә төрлелек ул - таркалырга дигән сүз түгел. Коръәндә болай диелгән: "Ий мөэминнәр! Барчагыз да, бер булып, Аллаһ арканына, ягъни Коръән хөкемнәренә ныклап ябышыгыз! Таркалып, аерылмагыз! Бер-берегезгә дошман идегез, Ул сезнең күңелләрегезне берләштерде. Аның нигъмәте белән кардәшләр булдыгыз" ("Әл-Гыймран" сүрәсенең 103 нче аяте)". Мөселман булуыбыз берләшүгә, килешеп эшләүгә нигез булып тора. Коръәндә язылган: "Мөселманнар - үзара кардәш".

Без бар кешегә ачык, һәркем белән мөгамәлә корырга, килешергә, сөйләшергә әзер. Әмма экстремизм һәм террорчылыкны яклаучылар белән бер юлда түгел. Башка кеше гомерен кыярга, исламны астыртын, сәяси максатларга файдаланырга берәүнең дә хокукы юк. Әһәмиятле сорауларга җавап тапканда бабаларыбыз тәҗрибәсенә, тарихи мирасыбызга таяначакбыз. Нәрсәнедер яңадан уйлап табарга кирәкми. Мөселманнарга хас проблемалар элек тә, йөз ел элек тә булган. Аларны чишү юлларын танылган татар дин әһелләренең хезмәтләреннән табарга мөмкин. Бу - безнең көч, безнең өстенлек.

Икенчедән, динебезгә чакыру һәм аның кыйммәтләрен халыкка җиткерү - төп бурыч. Кайберәүләр Татарстан мөселманнары арасында низаглар чыгармакчы булды. Бик күпләр "җиһад", "хиҗап", "шәригать" һәм башка дини терминнарны бутап, хәзрәтләр турында да пычрак сүзләр яза. Нәтиҗәдә, исламга карата тискәре караш туа башлады.

Без, гадәти кешеләр, барыбызга да кимчелекләр хас. Шулай да Аллаһы Тәгалә безгә дин әһеле булу җаваплылыгын биргән. Шуңа да үзгәрешне үзебездән башларга чакырам. Хәзрәтләрнең гыйлеме, гаделлеге, ихласлыгы барлык мөселманнарга карата фикерне формалаштыра. Газета, телевизор, радио аша да динебезгә чакырыйк, халыкка ислам хакыйкатен җиткерик. Диннең кеше тормышындагы, җәмгыятьтәге ролен аңлатыйк. Шулай итеп кенә тирә-юнебездәге кешеләргә йогынты ясый алачакбыз.



Өченчедән, татарлар - сан буенча Россиядә икенче урында торучы халык. Барыбыз да белә: татарлар Россиядә, беренчеләрдән булып, исламны кабул иткән. Дистә гасырлар дәвамында бабаларыбыз мәгариф, нәшрият һәм дин өлкәсендә әйдәп барганнар, Казан галимнәрен, дин белгечләрен дөнья күләмендә белгәннәр. Без дә бу эшне дәвам итәргә, барлык татарларны берләштерергә, толерантлыкны, тынычлыкны сакларга тиешбез. Бүгенге көндә Татарстан дөнья күләмендә киң танылу алды. Республиканың рухи үсешен, кыйммәтен без дә билгелибез, шул хакта да онытмасак иде.

Дүртенчедән, социаль хезмәт турында да берничә сүз әйтәсем килә. Аллаһ ризалыгы өчен иҗтимагый эш башкару - матур күренеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Аллаһ башкаларга карата мәрхәмәт күрсәтмәүчеләрне кичерми", - дигән. Иҗтимагый хезмәт аша мәрхәмәт кылыйк.

Халык бездән, имамнардан, нәзарәттән ярдәм көтә. Әлбәттә, берничә көн эчендә кыен хәлгә калган бөтен кешегә ярдәм итеп бетерү мөмкин түгел. Шулай да, әйдәгез, конкрет эшләр башкарыйк, мохтаҗларга, авыруларга сәдакалар җыюны, ашатуны оештырыйк, реабилитация, ярдәм итү үзәкләре ачыйк. Хәзер дә хәйрия эшләре белән шөгыльләнәбез, тик бу билгеле бер районнарда гына кебек. Социаль эшне киң җәелдерергә кирәк. Мөселман волонтёрлары хәрәкәтен башларга, мөселманнарны хәйрия чараларына җәлеп итәргә чакырам. Мондый төр эшчәнлек төрле караштагы мөселманнарны "уртак эш"кә җәлеп итә һәм аларның берләшүенә китерә ала. Хәйриячелек белән шөгыльләнү, социаль проблемаларны чишәргә тырышу өчен, ниндидер махсус белемнәр кирәкми, аны бары башларга гына кирәк.

Бишенчедән, фәнгә, мәгарифкә зур игътибар бирү мөһим. Мәгариф өлкәсе көчле, тәҗрибәле мөгаллимнәр, галимнәр тирәсенә тупланырга тиеш. Татар халкының күпгасырлык мирасы - яшьләрне рухи яктан тәрбияләүгә таяныч. Татар дини-рухи мирасын өйрәнгән, аны халыкара дәрәҗәдә белә торган дин белгечләре әзерләүне мөһим эш дип саныйм. Сез дә мине хуплarsыз, дип ышанам.

Шулай ук мәчетләрнең, мәхәлләләрнең матди ягын кайгыртырга кирәк. Дини уку йортларын тәмамлаучыларга эш табу һәм финанс яктан ярдәм итүне карарга тиешбез. Имамнар мәгърифәтчелек, дини кыйммәтләребезне тарату белән шөгыльләнсеннәр, вакытларын мәчет өчен акча эзләп йөрүгә исраф итмәсеннәр иде.

Безгә күп эшләр башкарырга туры киләчәк. Һәркемнең үз өлешен кертүен теләр идем. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен күркәм гамәлләр кылыйк, динебезгә хезмәт итик. Шул вакытта алдыбызга куйган максатларыбызга ирешербез.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә барыбызга да ныклык һәм сабырлык бирсен!

**Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе һәм мөфти вазыйфаларын башкаручы**

## ЯҢАЛЫКЛАР

### КАЗАНГА ХӘЙРИЯЧЕЛӘР ҖЫЕЛДЫ

**25 март көнне Казанда "2012 ел хәйриячесе" республика конкурсында җиңүчеләрне тәбрикләү тантанасы үтте.** Республикабыз күләмендә хәйриячеләрне, изгелек кылучыларны җыйган чарада Татарстан мөфтие вазыйфаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллинның урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров катнашты.

Әлеге чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов: "Хәзер без хәйрия эшчәнлегендә мәдәниятебез, тарихыбыз үзенчәлекләрен исәпкә алып, яңа сыйфат дәрәҗәсенә чыгарга тиеш. Без бергә булганда күп эшләр башкарырга сәләтле", - дип ассызыклады.

### МӘСКӘҮДӘ ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШТЫЛАР

**27 март көнне илебез башкаласында "Россиядә дини конфессияләрнең үсеш тармагы буларак, иҗтимагый хезмәт" дип аталган темага сөйләшү булды.** Россия Иҗтимагый палатасында узган әлеге "түгәрәк өстәл"не Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе урынбасары, Мәскәү һәм Чуашстан Республикасы мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов оештырды. Сөйләшүдә Татарстан мөфтие вазыйфаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллинның урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов та катнашты. Ул әлеге чарада катнашучыларны Камил хәзрәт һәм Татарстан мөселманнары исеменнән сәламләде. Аннары нәзарәт тарафыннан алып барылган иҗтимагый эшчәнлек турында сөйләде. Аерым алганда, Сөләйман мәчетендә урнашкан Күзләре начар күрүчеләр һәм сукырларны тернәкләндерү үзәге тәҗрибәсе белән уртаклашты, шулай ук нәзарәтнең социаль юнәлештә алып барачак эшләре белән дә таныштырды. Илдар хәзрәт ярдәмгә мохтаҗ төрле төркем кешеләргә, әйтик, инвалид балалар, наркоманнар һ. б. өчен алга таба төрле үзәкләр ачу нияте барлыгын җиткерде.

Сөйләшү барышында Әлбир хәзрәт Сөләйман мәчетендәге "Нур" нәшриятында нәшер ителгән "Зрячим о незрячих" китабын тәкъдим итте. Әлеге китапның авторлары - Күзләре начар күрүчеләр һәм сукырларны тернәкләндерү үзәге директоры Мәлика Гыйльметдинова һәм педагогика фәннәре кандидаты Гөлназ Сабитова.

### "ИСЛАМ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШИК"

**Татарстан мөфтие вазыйфаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллин мөхәррирлегендә "Расскажи мне об Исламе" дип аталган кыскача ислам энциклопедиясенең татарчага тәрҗемәсе дөнья күрде.** Исегезгә төшерәбез: әлеге китапның русчасы 2011 елда нәшер ителгән иде. Китап нәзарәтнең Голәмәләр шурасы тарафыннан расланган.

"Ислам турында сөйләшик" китабы ислам дине нигезләре, аның кыйммәтләре белән таныштыра. Дин белән бәйле күптөрле сорауларга бу китаптан җавап табарга мөмкин.

*Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан алынды*

# ХАКЫЙКЫЙ МИЗГЕЛ

***Билгеле булганча, кешенең чын йөзе кискен вакыйгаларда, хакыйкый мизгелдә ачыла. 2012 елның 19 июлендә республикабызда булган вакыйга барыбыз өчен дә ислам диненә хезмәт итүнең бик куркыныч эш булуын ачып салды. Узган гасыр башында булып узган большевиклар репрессияләреннән соң, беренче тапкыр без хәзер дини карашларыбыз өчен юк итә алуларын белдек. Шул вакытта булган вакыйгалар күп кенә мөселманнарны кыен хәлгә куйды: ислам диненә хезмәт итүне дәвам итәргәме, әллә үзеңне саклау турында уйларгамы?***

Белгәнебезчә, күпләр икенчесен сайлады. Алар арасында безнең җирлек өчен традицион булган ислам динен тотучылар да, чит илләрдән кергән агымнарга иярүчеләр дә бар. Юк, мин беркемне дә гаепләмим. Ләкин факт факт булып кала. Кайбер имамнар элек актив рәвештә алып барган эшләрен туктаттылар, кайберләре күпсанлы фикердәшләрен ташлап, жылы гарәп илләренә качты. Мин гаепле кешеләрне эзләмим. Бу бары тик өммәтебездә җитәкчелек итәргә омтылучы кешеләрнең кемнең кем икәнен күрсәтүче момент. Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) ислам диненә ачык чакыра башлаганнан бирле үтерү белән куркыткан Корәеш иленең һәм Мәккәдә яшәүче мәҗүсиләрнең эзлексез басымы астында булган. Ләкин Пәйгамбәребез (сгв) бер генә мизгелгә дә үз эшен ташламый. Иң элек ул үзенең сәхабәләрен Мәдинә шәһәренә күчереп коткара. Бары тик шуннан соң гына үзе һиҗрәт кыла. Бу Пәйгамбәребезнең (сгв) чын Сөннәте: берниди авырлыкларга карамыйча, ислам диненә хезмәт итүне дәвам итү; үзеңнән алда якыннарыңны кайгырту. Республикабызда булып узган вакыйгалар Сөннәткә чакырган кешеләрнең бу Сөннәтне үзләренең үтәмәүләрен күрсәтте.

Шулай да башка мисалларны күрәсе килә. Һәм алар безнең тарихыбызда бар. Бүген кайбер даирәләрдә өлкән буын мөселманнарына ни өчендер ихтирам күрсәтмәү гадәткә кереп китте. Ә бит нәкъ менә алар безнең өчен батырлык һәм фидакарьлек үрнәге булып тора. Динсезлек елларында башкалар карьера һәм дөнья малы артыннан куганда, алар ислам диненнән өйрәнгәннәр һәм дин юлында хезмәт итәргә курыкмаганнар. Ул еллар өчен бу үз-үзеңне җәберләүләргә дучар итү дигән сүз. Бүген дин юлына баскан шәкерт ниндидер өстенлекләргә, социаль гарантияләргә дәгъва итә ала. Элек исә дин юлында булучылар Аллаһы Тәгаләгә ышануларыннан башка бернәрсәгә дә өметләнмәгәннәр. Шулай да алар ислам диненә хезмәт итү юлын сайлаганнар. Көчле дәһрилек еллары аларның да иң яхшы якларын ачкан.

Бүген исә хакыйкый мизгел нәрсәне ача соң? Үзегез хөкем итегез. 19 июльдәге терактларга кадәр Татарстан мөфтие булырга теләүчеләрнең саны 12 иде. Терактлардан соң ярты ел вакыт узгач, мөфти булырга теләп, гаризаны өч кенә кеше язды. Мин беркемне дә гаепләмим. Бу бары тик хакыйкый момент кына.

Татарстан мөфтие урынына кандидатлар арасыннан, минем фикеремчә, иң тәвәккәл кеше чынбарлыкта бер генә: ул – Камил хәзрәт Сәмигуллин. Дөресен генә әйткәндә, бу яшь егеткә карап, мин халкым өчен горурлык хисе кичерәм, чөнки хакыйкый мизгел вакытында иң яхшы сыйфатларны гына ачкан аерым кешеләр булган. Моны безгә бары тик рухи ярлылыгыбыз кына күрергә мөмкинлек бирми.

**Рөстәм хәзрәт БАТЫР,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмаләр шурасы рәисе**

# Унсигезенче бәйге дә сөендерде

**27 март көнне Чаллыда балаларның республикакүләм унсигезенче Коръән уку бәйгесе үтте. Инде традициягә кергәнчә, ул ел саен язгы каникул чорында уздырыла. Бәйгегә җөмһүриятебез район-шәһәрләреннән генә түгел, ә бәлки республикабыздан читтә урнашкан төбәкләрдән дә яшь Коръән укучылар бик теләп киләләр. Ул бер үзенчәлекле бәйрәмгә әверелә.**

Быел да автошәһәрнең Ак мәчетенә җөмһүриятебезнең унбиш шәһәр-районыннан һәм Удмуртия Республикасыннан үз осталыкларын һәм гыйлемнәрен күрсәтергә дип, мөселманча киенгән 132 бала җыелды. Әмма катнашырга теләк белдерүчеләр күбрәк иде. Һава торышының кинәт катлауланувы сәбәпле, кызганыч, кайберәүләр килә алмады.

Бәйге Коръән укып башланды. Моңа үткән елларда үз яшь төркемендә даими төстә беренчелекне алып килгән Хәлил Хәйбрахманов лаек булды. 15 яшен тулу сәбәпле, үзе бу бәйгедә катнашмады. Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфулла, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең дәгъват эшләре буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы Нияз хәзрәт Сабиров, Татарстанның Кама буе төбәге казые, Ак мәчет имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Шәйхиевәли (бәйгене үздыру өчен яхшы шартлар тудыручы), Чаллы шәһәре Башкарма комитетының җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге башлыгы Рөстәм Галиуллин сәламләде һәм яшь Коръән укучыларга уңышлар теләде.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*



# Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең ярдәмчеләре белән таныштырды

**22 март көнне Татарстан мөфтие вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллин журналистлар белән аралашу барышында үзенең ярдәмчеләре белән таныштырды. Алар - Казанның Сөләйман мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмаләр шурасы рәисе, РИИ проректоры Рөстәм хәзрәт Батыров һәм Казан ислам колледжы директоры урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров.**



Илдар хәзрәт Баязитов мөфтияттә социаль юнәлешне дәвам итәчәк, яшьләрне, мөселманнарны берләштерә торган бүлекне җитәкләячәк. "Социаль өлкәгә караган эш бик күп. Безнең алда зур бурычлар тора. Социаль эш ул - ниндидер хәйрия акцияләре һәм хәйрия ашлары гына дигән сүз түгел әле. Ул - көн саен шактый көч түгеп башкарыла торган эш. Без аны тиешле дәрәҗәгә җиткербез дип уйлыйм. Бу - исламның йөзе, һәр мөселман социаль яктан имин булырга тиеш. Социаль хезмәт камил дәрәҗәгә күтәрелгән очракта гына, без исламның асылын, аның ни икәнлеген белә алачакбыз дип уйлыйм. Шуннан соң мөселманнарга гына түгел, гомумән, республикада яшәүчеләргә җиңелрәк булачак. Нинди милләттән һәм нинди дин тотуына карамастан, мөселманнарның кешеләргә ярдәм итәргә тиешлеге турында бик күп хәдисләр бар", - дип, Илдар хәзрәт эш юнәлешләрен билгеләп үтте һәм Камил хәзрәткә ышаныч күрсәткән өчен рәхмәтен белдерде.

Рөстәм хәзрәт Батыров фәнни эшчәнлек, халыкара элемтәләр өчен җавап бирәчәк. "Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте алдында бүгенге көндә бик күп бурычлар тора. Өстенлекле юнәлешләрнең берсе - белем бирү, бу мөселман фәне өлкәсенә карый. Татарстанда соңгы еллар эчендә мөстәкыйль мөселман мәгариф системасы барлыкка килде. Мәгърифәтчелекне тарату, тирән белем бирү халкыбызның гасырлар буена алып барган рухи тормышының нигезе булып тора. Әмма бу системаның билгеле бер тәртибе булмаган: ничек бар, шулай төзелгән. Ничек эшли алганнар, шулай башкарганнар - шуннан тулы бер структура барлыкка килгән. Финанс һәм билгеле системага салынган методик ярдәм булмаган. Бүгенге көндә санны сыйфатка үзгәртергә кирәк. Моңда заманча белем бирү технологияләрен мөселман белем бирү системасына кертү бурычы тора. Хәзерге вакытта Камил хәзрәт боерыгы белән Укыту-методик берләшмә (Учебно-методическое объединение) төзелде. Анда республиканың бөтен мөселман уку йортлары керәчәк һәм дини белем бирү стандарты эшләнәчәк. Бу безнең уку йортларына сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелү мөмкинлеге бирәчәк", - дип белдерде Россия ислам институтының фәнни эшләр буенча проректоры Р.Батыров. Шулай ук ул моңарчы билгеле булмаган татар галимнәренең ислам буенча язылган хезмәтләрен өйрәнеп, аларны бастырып чыгару зарурлыгын билгеләп үтте. "Бүген килеп чыккан проблемаларны хәл итү юллары бу хезмәтләрдә күптән инде күрсәтелгән булган", - диде ул.

Нияз хәзрәт Сабиров исә Экспертлар советы, дәгъват алып бару бүлеге һәм Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе белән элемтәләр урнаштыру өчен җаваплы булачак. Ул, халыкка исламның пакьлеген, матурлыгын күрсәтү зарурлыгын билгеләп үтеп, алга таба да яшьләргә әхлак тәрбиясе бирүдә зур игътибар ителәчәге турында әйтте.

**Римма ГАТИНА,**
**www.tat.tatar-inform.ru**

# ИМАМ, ТАРИХЧЫ, ЭТНОГРАФ

**Имам, тарихчы, этнограф Корбангали Халидинең вафатына быелның 14 мартында йөз ел тулды. Ул, беренчедән, асыл ватаныннан еракта, мөһаҗирлектә яшәп, дин эшлеклесе буларак, төрле төрки-мөселман халкын тәүфыйк-сәгадәт юлына күндерүдә, аларга белем-тәгълим бирүдә бибәһа игелекле хезмәт куйган могтәбәр затларның берсе. Икенчедән, Урта Азиянең, Шәркый (Көнчыгыш) Төркестанның, шул җирләрдә хәят кичергән казакъ, кыргыз, уйгыр һәм башка милләтләрнең үткәндәге һәм үзе яшәгән чордагы тарихын, көнкүреш рәвешләрен, гореф-гадәтләрен тәфсилле өйрәнеп-тикшереп саллы хезмәтләр язган галим дә.**



Корбангалинең атасы - чыгышы белән Казан өязенең Орнашбаш авылыннан (ул хәзер Татарстан Республикасының Арча районы Утар-Аты җирле үзидарәсенә карый). Халид бик яшьли казакъ арасында сәүдә белән шөгыльләнә. Казакъларның Русия карамагына керәчәкләре беленгәч, ул үзенең берничә иптәше белән Ташкент якларына китә. Тиешле рөхсәт белән шәһәр янындагы Салар суы буенда җир алып, өйләр корып, иген игеп, сигез ел гомер кичерәләр. Әмма Ташкент хакиме Мөхәммәт Шәриф белән Ширали хан арасында низаг чыгып, татарлар авыр хәлдә калалар. Халиднең анда бер хатыны вафат була, икенчесе белән аерылышалар. Аннан соң алар Аягүз (Сергиополь) шәһәренә күченеп китәләр.

Халид анда Бибигафифә исемле кызга өйләнә һәм 1846 елның 1 ноябрендә аларның уллары Корбангали туа. Малай башлангыч белемне үзләрендәге мәдрәсәдә Мөхәммәтсадыйк бине Исмәгыйль исемле мулладан үзләштерә, аннан соң, Семипалат шәһәренә барып, Гобәйдулла улы Габделҗәббар мәдрәсәсендә белем алуын дәвам иттерә. Ул анда гарәп, фарсы һәм төрек телләрен өйрәнә, ә казакъчаны, уйгырчаны камил белгән. Коръәнне яттан белеп, карыйлык дәрәҗәсенә ирешә.

Аягүздә утыз ел гомер кичергәннән соң, гаилә башта чик буендагы Бахты авылына килеп урнаша, ә аннан Кытайның Шенҗан провинциясендәге Тарбагатай округының админстратив үзәге булган Чүгүчәк (Чәүчәк) шәһәренә күчenә.

1879 елда Халид хаҗга бара. Истанбул шәһәрендә ул солтан Габделхәмит тарафыннан кабул ителә. Мөселман өчен фарыз булган гамәлләрнең монысын үтәп кайткач, тагын җиде ел яшәп, 1886 елда вафат була.

Ул Ташкент шәһәрендә Ишанхан, Төрехан исемле атаклы остазларның хезмәтендә булып, аларның хәер-фатыйхаларын да алган булган икән. Шәрәфи бай дигән бер дусты соңыннан, Салар буенда калган аның өен сатып, акчасын гаиләсенә җибәрә.

1874 елда егерме сигез яшьлек Корбангали карыйны Чүгүчәк мәчетләренең берсенә имам, ә 1881 елда шәһәрдә һәм тирә-як далаларда яшәүче мөселманнарга (үзләренең аерым Җәмигъ мәчете, имамы һәм казые булган дөңгәннәрдән башка) казый итеп билгеләләр.

Танылган тюрколог Н.Ф. Катанов (1862-1922) 1891 елда Шәркый Төркестанга гыйльми сәфәре вакытында, Чүгүчәктә булып, Корбангали хәзрәт белән дә очраша, аңардан үзенә кирәкле мәгълүмат язып ала. Соңыннан ул матбугатта бастырган "Йоклаган җиде әүлия турында татар хикәятләре" дигән мәкаләсендә К.Халидинең "Тарихы җәридәи җәдидә" ("Яңа тарихи язмалар") дигән китабында китерелгән вариантка да берникадәр анализ ясый. Аерым алганда, Н.Катанов болай дип яза: "Ул (Корбангали. - Р.И.) йоклаган җиде әүлиягә зиярат кылырга барган һәм юлда төрле, шул җөмләдән, әлеге йоклаган җиде әүлия турында да хикәятләр җыйган. Китабында ул Чүгүчәктән Торфанга һәм Кара хаҗига сәяхәтен бәян итә. Ул нәкъ Коръәндә әйтелгән шул йоклаган җиде әүлиягә зиярат кылуына бик нык ышана".

Корбангали хәзрәт Чүгүчәкне? абруйлы байларыннан берсе Рамазан Чанышев белән 1897-1898 елларда егерме ай хаҗ сәфәрендә була. Юл уңаенда Истанбулда махсус тукталып, танылган төрек галим-голәмасе белән очрашалар. Алар арасында, мәсәлән, Әхмәт Мидхәт тә була. Аурупа дәүләтләрендә булып, андагы күп кенә шәһәрләр белән дә танышалар.

Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә яшәп, мәгърифәт тарату эше белән шөгыльләнгән якташларыбыз турында да яза ул. Мәсәлән, Мөхәммәтзариф ибне Ясин исемле бер ватандашыбыз Пәйгамбәребез (сгв) мәчетендә байтак еллар балаларга сабак укыткан икән. Ә Спас өязендәге Яңа Чаллы авылында туган Габделсаттар хаҗи Мәдинәдә "Казанлы" дигән мәдрәсә төзеттергән.

Корбангали хәзрәтнең беренче китабы, инде алда әйтелгәнчә, "Тарихы җәридәи җәдидә" дип атала. Ул Казан сәүдәгәре Шәмсетдин Хөсәен углының матди ярдәме белән 1889 елда Казан университеты табыгханәсендә нәшер ителә. Әлеге хезмәт автор тарафыннан Шәркый Төркестанның эчке төбәкләренә - Көһнә-Торфан шәһәренә кадәр ясалган сәяхәтләре вакытында тупланган юлъязмаларга, материалларга нигезләнеп язылган. Анда төрле, аерым алганда, Манас, Санчы, Өремче, Дөнче, Торфан, Астана, Лучен шәһәрләре, изге урыннар, хуҗалар, шәехләр турында кызыклы мәгълүмат китерелә. Әүвәл Коръәндә әйтелгән, соңыннан төрки язма истәлекләрдән Насреддин Рабгузыйның "Кыйссасел-әнбия"сендә (XIII гасыр) урын алган һәм, ниһаять, XIX йөз татар әдибе Закир Һадига (1863-1933) "Яңа әсхабе кәһәф" (Әсхабе кәһәф - тау тишеге, мәгарә) (1908) дигән әсәр язарга нигез булган "Әсхабе кәһәф", ягъни йоклаган җиде әүлия турында кыйсса шулай ук китапта аерым урын алган.

Автор үзе күргәннәрне зур игътибар, төгәллек белән теркәп барган. Менә ничек яза ул: "Торфандан түрт таш, ягъни утыз вёрстлар чамасында улыр Астана шәһәре вар..."

Шунысын да әйтергә кирәк, Корбангали хәзрәтнең абруе үзеннән алда йөргән. Чөнки аны һәр урында төрле милләт халыклары хөрмәтләп каршы алганнар, аңа мөкатдәс эшендә теләп ярдәм иткәннәр һәм зурлап озатып калганнар.

Галимнең икенче китабы "Тәварихы хәмсәи Шәркый" ("Шәрекънең биш иле тарихы") дип атала. 799 битле бу хезмәт 1910 елда Казанның "Үрнәк" басмаханәсендә нәшер ителгән. Аның ничек язылуын Корбангали хәзрәт болай тасвирлый: "...екерме йылдан зиядә буңа даир әхбар вә буңа мөтәгалликъ асәрләре җәмегъ вәҗем кыйлыб, җөмләсенең зөбдәсене бу китабчада дәреҗ әйләдем..." (...егерме елдан артык моңа караган хәбәрләр һәм моңа бәйләнешле әсәрләрне җыеп, барысының иң яхшысын бу китапчада теркәдем...). Китап ахырында гарәп телендә ул, тагын да конкретлаштырып, бу китапны үзенең имам вазыйфасында утыз алтынчы, ә казыйлык итеп сайлануына егерме сигезенче елында - һиҗри 1327 (1905 милади) елның 28 шәгъбанында тәмамлавын яза.

Корбангали хәзрәт әлеге хезмәтен үзе күреп-белгәннәргә, язма чыганакларга һәм төрле катлау кешеләрдән ишеткән хәбәрләргә нигезләнеп язган. Бу хакта ул менә ничек белдерә: "Ошбу әхбарның (хәбәрләрнең) бер рависе (бәян итүчесе) Мәргыйнәни карый Хәмид әфәнде хикәя әйтер ки..." Язма чыганакларга килгәндә исә, болай ди: "Хытай тәварихындан тәрҗемә улынан әхбар әгәрчә ихтисар (сөземтә чыгару) үзрә язылмышдыр. Ләкин безем әһле ислам арасында Чин әхвалендән бәхәс идән буйлә бер мәҗмуга бу ан кадәр күрелмәдекдән буңа бераз мобаһат итсәм (мактансам) җаиздер (ярый торгандыр). Хытай тәварихын Өремче бәлдәсендән (шәһәреннән) кәтүрән тиҗар (сәүдәгәр) Әшрәф Хөсәен углы Чанышев иде ки, бер лөгать китабы илә бәрабәр безә һәдийә итмешде. Бундан мөкаддәм (элек) дөңгәне имамнарыннан вузурган, ягъни мәхкәмә кешеләреннән сорап-белеп хәйле (күп) хәбәрләр язмыш исәм дә, хөрмәтле Хөсәен әфәнденең кәтүрдеге тәварих ул хәбәрләрнең масадакы улдыгычөн (туры килгәне өчен) мәзкүр Хөсәен әфәндиә зийадә (артык) шөкеранаме мәүҗеб әйләмешдем (нигез итәм)". Ә "Үзбәк иле" дигән төшенчә турында сүз алып барганда, "Мөстәфадел-әхбар сахибенең ифадәсендә будыр" дип, үзенең фикерен танылган дин реформаторы, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818-1889) "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә болгар" ("Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр") дип аталган биобиблиографик характердагы фундаменталь хезмәтендәге мәгълүмат белән дәлилли.

Бу китапта Корбангали хәзрәт, казакълардагы туй йолаларын тасвирлауга зур урын биреп, төрки халыкларда киң таралыш алган "Яр-яр" җыры турында кызыклы мәгълүмат белән бергә, аның төрле акыннар тарафыннан әйтелгән вариантының текстын да урнаштырган. Шулай ук казакъларга гына хас "Бит ачар" җырының бер үрнәген дә тәкъдим иткән.

Анда шулай ук күп кенә шигырь үрнәкләре дә урын алган. Биредә без аларның берсенә генә игътибарны юнәлтү белән чикләнәбез:

*Көфер вә ислам бәрабәр*
*гадел-инсафдыр нәкый,*
*Бәндәйә зәмман кафидер*
*фәгълидә золым-шәкый.*
*Бәс буныңчөн өммәтенә диде ул насих Рәсүл:*
*"Көфер илә бакый улыр мөлек,*
*золым илә улмаз бакый".*

Бу мотивны без XVI йөз татар шагыйре Мөхәммәдьярның "Нуры содур" ("Күңелләр нуры") поэмасында да очратабыз. Ул анда болай яңгырый:

*Көфер берлә мәмләкәт булмас харап,*
*Золым берлә йыкылыр улус йөдәп.*

Димәк, биредә әдәбиятчыларга да тикшеренү өчен кызыклы материаллар бар икән.

Күренекле дин галиме, тарихчы, педагог, язучы, журналист Ризаэтдин бине Фәхретдин (1859-1936) әлеге хезмәтне болай бәяли: "Бу китапта бәгъзе бер әкият вә хорафатлар истисна иделсә (чыгарма ителсә), әлхак, гүзәл бер әсәрдер. Бик файдалы вә бу китаптан башка йирдә күрелмәячәк мәгълүмат күптер. Мөәллифнең гыйлем вә фазыйленә, зиһен вә хатере саф вә иркен-легенә дәлаләт кылыр..."

Автор үзе белдергәнчә, әлеге китапның дәвамы буларак тагын бер хезмәт язу уйланылган булган. Хосусан, ул бу хакта болай ди: "Имди бу китабымызы бурада (монда) тәмам идеб туктадык. Йукарыда вәгъдә идийән бәгъзе сүзләр булса, бундан соңрагы китабымыза дәреҗ иделеб иншаэ Аллаһ Тәгалә Раббел-галәмин".

Әлеге китапның аерым өлешләрен Б.Төтенаев һәм А.Жолдасов, хәзерге казакъ теленә тәрҗемә итеп, "Тауарих хамса (Бес тарих)" исеме белән 1992 елда Алматыда нәшер иттеләр.

Борынгы язма истәлекләрне өйрәнүче Габит Зүлкаровның "Білімдіден шыңған сөз" ("Белемледән чыккан сүз") дип исемләнгән мәкаләсендә ("Аңиңат" журналы, 2012 ел, № 3) Корбангали хәзрәтнең дүрт улы һәм дүрт кызы булуы әйтелә. Аның варислары хәзерге вакытта Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан республикаларында гомер итә. Аягүз шәһәрендә генә дә өч оныгы һәм тугыз оныкчыгы яши икән. Каланың 58 нче урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән (инде мәрхүм) Рәхилә Халидовада әтисе белән бабасының төрле елларда алдырылган сурәтләре сакланган булган. Ә Алматыдагы Республика китапханәсендә баш библиограф булып эшләгән оныкчыгы Сания Теңизбаева исә үз вакытында олы бабасы файдаланган ике фарфор тәлинкәне Аягүздәге борынгы тарихи ядкарьләр музеена бүләк иткән.

Академик Миркасыйм Госманов (1934-2010) үзенең хезмәтләрендә бәян иткәнчә, ул 1987 елда Ташкентта булганда Корбангали хәзрәтнең онытгы Мәсгут абзыйның хатыны Рәйханә апа, Фрунзе (хәзерге Бишкәк) шәһәреннән махсус килеп, аңа бабасының кайбер мөһим кулъязмаларын тапшыра. Аннан күренгәнчә, имамның нәсел башы булган Төрекмән баба тумышы белән Хива ханзадәләреннән булып, язмыш аны Казан якларына, ягъни Сәрдә авылына китергән һәм ул анда өйләнеп, төпләнеп калган. Ә Корбангали Халидинең бертуган апасы Бибизаһидәнең әнисе Бибихәдичә Миркасыйм аганың әтисе ягыннан бабасы Габделбари хаҗиның җәмәгате булган икән...

Үткән ел Аягүз шәһәренең бер урамына Корбангали Халиди исеме бирелде. Аның исеме рус телендә нәшер ителгән "Татар энциклопедия сүзлеге"нә (1998) дә кертелгән.

Корбангали Халидинең югарыда аталган китапларын, Казакъстан Фәннәр академиясендә һәм шәхси кулларда саклана торган башка хезмәтләрен гамәлдәге татар хәрефләренә күчереп, аларны тиешле аңлатма-шәрехләр белән тулыландырып нәшер итү татар гуманитар фәнендә кичекмәстән хәл итәсе мәсьәләләрдән саналырга тиешле. Чөнки алар үткәндәге гомумтөрки тарихны өйрәнүдә кыйммәтле чыганакларның берсе булып тора.

**Рәмил ИСЛАМОВ,**
**филология фәннәре докторы**



# Унсигезенче бәйге дә сөендерде

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

Бәйге 4 яшь төркемендә барды. Җиңүчеләр балл системасы нигезендә билгеләнде. Быелгы бәйгегә иң яхшы әзерлек белән Түбән Кама һәм Әлмәт вәкилләренең килүе ачыкланды. Түбәнкамалылар 5 беренче призлы урынга лаек булса, әлмәтлеләр ике төркемдә беренчелекне яулады. Моннан тыш Түбән Кама шәһәренең 5 яшь Коръән укучысы 2, 3 нче призларны бүлеште. Ә Әлмәт вәкилләре 6 икенче-өченче призларны да яулады. Бәйгенең беренче призына түбәндәгеләр лаек булды: Әмин Әүхәдиев (7 яшькә кадәр, Түбән Кама), Әхмәт Мирсәетов (10 яшькә кадәр, Әлмәт), Габдрахман Әүхәдиев (13 яшькә кадәр, Түбән Кама), Кәрим Хәсәнов (15 яшькә кадәр, Теләче); Мәрьям Әхмәтшина (7 яшькә кадәр, Түбән Кама), Гайшә Хәйбрахманова (10 яшькә кадәр, Түбән Кама), Асия Мөфлихунова (13 яшькә кадәр, Әлмәт), Әүхәдиева Фатыйма (15 яшькә кадәр, Түбән Кама). Икенче призны яулаучылар: Газизов Ильяс (7 яшькә кадәр, Ижевск), Рәшит Әхмәтҗанов (10 яшькә кадәр, Түбән Кама), Хәмзә Хәйбрахманов (13 яшькә кадәр, Түбән Кама), Сухраб Сиражетдинов (15 яшькә кадәр, Әлмәт); Зәйнәб Хәйретдинова (7 яшькә кадәр, Түбән Кама), Сафия Ханнанова (10 яшькә кадәр, Әлмәт), Асия Мөфлихунова (13 яшькә кадәр, Әлмәт), Гайшә Әүхәдиева (15 яшькә кадәр, Әлмәт). Өченче призлы урынны яулаучылар: Хәниф Гомәров (7 яшькә кадәр, Түбән Кама), Мөхәммәд Әхмәтшин (10 яшькә кадәр, Түбән Кама), Илназ Шәрәпов (13 яшькә кадәр, Балтач), Фирдәвес Бакиев (15 яшькә кадәр, Әлмәт); Алия Газизова (7 яшькә кадәр, Ижевск), Нажия Мөфлихунова (10 яшькә кадәр, Әлмәт), Алия Галәветдинова (13 яшькә кадәр, Казан), Рәзинә Сафина (15 яшькә кадәр, Алабуга).

Призлы урыннарга дәгъва белдерүчеләр арасында баллары тигез булу очраклары да булмады түгел. Мәсәлән, 13 яшькә кадәрге малайлар төркемендә икенче призлы урын өчен Хәмзә Хәйбрахманов һәм Илназ Шәрәпов арасында кискен көрәш барды. Жюри аларны ике мәртәбә кабатлап укытырга мәҗбүр булды. Чак кына өстенлек белән Хәмзә җиңде. Илназ Балтач районында узган Коръән бәйгеләрендә дә даими җиңүче икән.

Өйлә намазыннан соң җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды. Мөфтият вәкиле Нияз хәзрәт һәр төркемдә 4, 5 нче призлы урыннарны да билгеләргә тәкъдим итте. Ул моның өчен бүләкләр дә алып килгән иде. Һәм шулай эшләнде дә. Бүләкләнүчеләр саны тагын 16 кешегә артты. Моннан тыш ике иң яшь катнашучы билгеләнде. Мондый исемгә 3 яшьләрен тутырган Әлмәт районының Колшәриф авылыннан Мәдинә Ханова һәм Чаллыдан Хәсинә Хәйруллина лаек булды. Аларга махсус бүләк тапшырылды. Ә гомумән алганда, бәйгедә катнашучы беркем дә бүләксез калмады. Калганнарга дини әдәбият таратылды. Аннары бәйге хөрмәтенә аш мәҗлесе үтте. Кыскасы, унсигезенче бәйге дә бик сөендерде, балаларыбызның Аллаһ Китабын дөрес итеп уку буенча зур тырышлыклар куюын һәм уңышка ирешүен күрсәтте.

## КАМА БУЕ ТӨБӘГЕНДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА!

**Быел хаҗ кылырга ниятләгән хөрмәтле мөселман кардәшләребез!**

**2013 елның 30 мартында Чаллы мөхтәсибәте "ДУМ РТ Хадж" вәкиле катнашында һиҗри ел исәбе буенча 1434 ел хаҗына багышланган беренче җыелыш үткәрәчәк. Чара Чаллы шәһәренең "Нур-Ихлас" мәчетендә (48 нче комплекс, 9 / Чулман проспекты, 108/5) көндезге сәгать унбердә (11.00) башланачак. Очрашу барышында катнашучылар үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап таба алачак.**

**Алга таба да мондый җыелышлар һәр айның соңгы шимбәсендә узар дип көтелә. Белешмәләр өчен телефон: +7 (8552) 56-65-99 (мөхтәсибәт).**

# Мөслимәләрнең эшлекле стиль үзенчәлекләре

**Эшләүче яки эшкә урнашырга теләүче мөслимәләргә, квалификацияле һәм җаваплылык тойгысына ия булган хезмәткәр тәэсире калдыру өчен, җитди, пөхтә булып күренергә кирәк. Тик эш костюмы сайлап алу мөмкинлеге чикләнгән, кибетләрдә, кагыйдә буларак, хатын-кызларның билен, фигурасын ачыклап яки аңа сыланып ук торган жакетлар һәм тар чалбарлар гына (эшләүче, эшлекле хатын-кызларга нәкъ менә шуларны) тәкъдим итәләр.**




Бу хәлдән чыгар өчен гади костюм ярдәм итәр кебек, чөнки ул уңайлы, кырыс тоннарда тегелгән. Ләкин, аңлашылганча, хәзерге офис модасы, бүгенге җәмгыятьтәге мораль белән бергә, әхлак баскычлары буйлап түбәнгә тәгәрәп бара шикелле. Мәсәлән, кырыс тонда тегелгән киң, кара офис чалбары эзләп карагыз. Бар җаваплылыгым белән әйтә алам: сезгә бу очракта чалбар бәясеннән дә күбрәк көч сарыф итәргә туры киләчәк. Хатын-кызлар эш урынында ир-ат коллегаларының аларга карата килешсез мөнәсәбәтләреннән, аларга бәйләнүләреннән зарланырга яраталар. Тик, шуңа да карамастан, үзсүзләнеп, һаман да кыска карандаш-итәкләр һәм тирән декольте блузкалар киеп йөрүләрен дәвам итәләр. Шуннан кибетләрдә сорау-тәкъдимнәрдән ассортиментлар килеп чыга.

Ә мөселман хатын-кызларына нишләргә соң? Шәригать кануннарына туры килгән, эшлекле, тиешле образны ничек тудырырга? Бу вакытта ир-атларга да бәйләнергә урын калмас иде. Беренче сөйләшү яки эшлекле очрашу моменты сезнең турыда нинди фикер калуын билгели дә бит инде. Бу очракта безнең ратып кигән көндәлек трикотаж киемнәребез бер дә килешеп бетми. Эшлекле стиль шунысы белән дә яхшы: аның костюм тукымасы фигурага "сыланып тормаска" мөмкинлек бирә, ул җитәкчеләр, хезмәттәшләр, клиентлар белән аралашкан вакытта җыйнаклылык, пөхтәлек фикере калдыра.

Шунысы яхшы: бүгенге көндә кискен консерватизм образында, кагыйдә буларак, зарурлык юк, ә мөселман хатын-кызларына эш костюмын гади элементлардан формалаштыру өчен мөмкинлекләр бар: озын, кырыс тондагы күлмәк, блуза, костюм тукымысыннан тегелгән туры итәк. Моңа иркен тегелгән жакет, трикотаж блейзерны да өстәргә була. Соңгысын сайлап алу мөмкинлеге хәзер зур, төсләр гаммасы һәм фасоны буенча туры килгәнен табарга була.

Быелгы язда ачык төсләргә өстенлек бирелә: ачык кызгылт-шәмәхә, саргылт-ал, мандарин төсе, зөбәрҗәт яшел, шул ук вакытта, нәфис, йомшак, җиңел кабул ителә торган тоннарга: коңгырттрак, соргылт, күк, ал. Ләкин эш костюмында андый үзенчәлекле төсләргә өстенлек биргән вакытта, гомуми образыгызның ачыклыгы белән артык җилбәзәк һәм романтик булып тоелырга тиеш түгеллеген дә онытырга ярамый. Бу сезне эш бирүче һәм клиентлар алдында төпле, нигезле һәм ышанычлы кеше итеп күрсәтми, ягъни, әгәр дә инде сез ачык кызгылт-шәмәхә блейзер сайлап алгансыз икән, костюмыгызның аскы өлеше һәм аксессуарларыгыз - сумка, перчаткаларыгыз тыныч һәм кырыс тоннарда булырга тиеш: кара, коңгырт-соры, соры, коңгырт-зәңгәр. Андый вариант эш урынында кырыс киенү әдәбе (дресс-код) урнаштырылмаган урыннарда ярый.

## Нинди яулык сайларга?

Яулыкны сайлап алу костюмның гомуми фактурасындагы төсләр гаммасына бәйле. Эшлекле очрашулар вакытында "ураган инде шунда" дип әйтергә юл калдырмый торган, тонык атлас, ефәк һәм синтетикадан, аларга охшаган материаллардан булган яулыкларга өстенлек бирегез. Яулыкны башка бәйләгән вакытта тыйнаклыкка әһәмият итәргә кирәк, төрекчә ябу аеруча яхшы, ул вакытта йөз ачык кала, алай итеп бәйләү пөхтә санала: артык сырлары, бөгелмәләре булмый. Мондый алым әңгәмәдәшеңнең артык игътибарын җәлеп итмәячәк, ә киресенчә, ул үз игътибарын сезнең башыгыздагы яулыкка, андагы күпләгән чүпрәк кисәкләренә түгел, бәлки сезнең даһи бизнес-идеяләрегезгә юнәлтәчәк. Хәер, әңгәмәдәшегез сезнең киемегезгә, кыяфәтегезгә барыбер күз төшерәчәк, шуңа да үзегезнең башъяулыгыгыздан кыенсынырга кирәкми. Ул - безгә Аллаһы Тәгаләнең күрсәтмәсе. Үзегезне ышанычлы һәм лаеклы тотыгыз, бу һәрвакыт хөрмәт уята.

Безгә Төркия дәүләтененең беренче эшлекле хатын-кыз (леди) образы ошый (сез рәсемдә Хәерниса Гүлне күрәсез). Бу - безнең караш буенча, эшлекле кием белән хиҗапның бер-берсенә каршы килмәвен дәлилли торган образ.

Эшегездә уңышка ирешегез һәм шуны һәрчак исегездә тотыгыз: мөселман кайда гына булмасын, нәрсә генә эшләмәсен, ул һәрвакыт барысыннан да яхшырак булырга тиеш! Шуны онытмасак иде: үзебезнең тәртибебез, җаваплылыгыбыз аша безгә һәммәсен: Аллаһ тарафыннан бар ителгән җирнең, күкнең һәм динебезнең нинди бөек һәм гүзәл булуын башкаларга күрсәтәбез бит.

**Резеда СӨЛӘЙМАН,**
**www.rezedasuleyman.com**

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 13 (182) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35396.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 28 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).